**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 26 мартындагы 9-37 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль зоналар – күпкатлы торак төзелеше зонасы (Ж4) (45 номерлы контур), табигать территорияләре зонасы (Р1) (87 номерлы контур) һәм урам-юл челтәре ярдәмче зонасы (УДС) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20, 43 статьялары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 августындагы 3257 номерлы «Казан шәһәре Думасының Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориаль зоналар – күпкатлы торак төзелеше зонасы (Ж4) (45 номерлы контур), табигать территорияләре зонасы (Р1) (87 номерлы контур) һәм урам-юл челтәре ярдәмче зонасы (УДС) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында»гы, 2022 елның 8 апрелендәге 1011 номерлы «Бертуган Батталовлар урамындагы территорияне планлаштыру проектын раслау турында»гы карарларын һәм 2024 елның 12 декабреннән алып 2024 елның 26 декабренә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә территориаль зона – күпкатлы торак төзелеше зонасы (Ж4) (45 номерлы контур) чикләренә 16:50:171202:2963 кадастр номерлы, мәйданы 5192 кв.м булган җир кишәрлеген кертеп, территориаль зона – табигать территорияләре зонасы (Р1) (87 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.2. территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә территориаль зоналарның – күпкатлы

торак төзелеше зонасы (Ж4) (45 номерлы контур), табигать территорияләре зонасы (Р1) (87 номерлы контур)  чикләрен үзгәртергә;

1.3. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның территориядән югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.4. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.5. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 4 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 26 мартындагы
9-37 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**Ж4 - 45**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы


**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| (алсу) | О2 | Белем бирү объектларын урнаштыру зонасы |
| (яшел) | Р1 | Табигать территорияләре зонасы |
| (сары) | Ж4 | Күпкатлы торак төзелеше зонасы |
| (чик) | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чикләре |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**

Казан шәһәре Думасының
2025 елның 26 мартындагы
9-37 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр:**

**Ж4 - 45**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| Төс | Индекс | Территориаль зона төренең атамасы |
|---|---|---|
| | Ж4 | Күпкатлы торак төзелеше зонасы |
| | О2 | Белем бирү объектларын урнаштыру зонасы |
| | Р1 | Табигать территорияләре зонасы |

**Территориаль зоналарның ярдәмче зоналары**

| Төс | Индекс | Территориаль зонаның ярдәмче зонасы төре атамасы |
|---|---|---|
| | УДС | Урам-юл челтәре ярдәмче зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы территориаль зоналарның урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре ярдәмче зоналары күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы фрагменты |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**